Бала сөйләшергә өйрәнә.

Гаиләдә бала туган көннән соң, гадәттә, аның һәр кылган гамәле эти-әни, әби-бабай, туганнар өчен иң күп сөйләнә торган темага әверелә: менә ул елмайган, кемнәндер ятсынган, кемнедер таныган, үрмәләгән, басып торган һәм башкалар. Баланың беренче әйткән сүзен ишетү аеруча күңелле.

Баланың сөйләме үсешендә кул моторикасының зур роль уйнавын истән чыгармаска кирәк. Гади генә итеп аңлатканда, баш миенең сөйләм һәм хәрәкәтне көйләүче зоналары янәшә урнашкан, шуңа күрә яхшы үсеш алган вак кул моторикасы сөйләм үсешенә дә уңай йогынты ясый. Шакмакларны, шарларны бер савыттан алып икенчесенә тутыру уенын күрсәтергә, бергәләп уйнарга кирәк. Пирамида алып, аның балдакларын кигезергә өйрәтегез. Машина йөртергә өйрәткәндә, “би-би”, “трр” авазларын кабатлагыз. Ә курчакны бергәләп “йоклатыгыз”: ә-ә-ә-ә-ә-ә. Күргәнегезчә, балага уенчык алып бирү белән генә чикләнергә ярамый, ә аның белән уйнау мөмкинлекләрен дә күрсәтергә, баланың сөйләмен үстерүгә ярдәм итәрлек итеп оештырырга кирәк. Кул чәбәкләү (ладушки), бармак уеннарының сөйләм үсешенә ярдәме бик зур. Юкка гына элекке вакытларда бала караучылар, әбиләр бармак уеннарына зур игътибар бирмәгән.

Тулысынча сау-сәламәт туган бала 3 яшенә инде ана телен тулысынча үзләштерә, 4 яшенә [ р ] , [ ш ] авазларын да дөрес әйтә ала. Моның өчен тагын бик мөһим шарт бар: белгечләр әйтүенчә, 3 яшенә кадәр бала үз ана телендә тәрбия алырга тиеш. Безнең шартларда бу – бик катлаулы эш, ләкин ничек кенә булмасын, бу – фәнни яктан расланган факт.

Үз вакытында күрсәтелгән ярдәм күп кенә җитешсезлекләрне уңышлы төзәтергә мөмкинлек бирә.